ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2017 ел № 21/16

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 08 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 04 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 09 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 05 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктын өстәргә:

«4.1)«Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә җылылык белән тәэмин итү системасының үсеше, ышанычлылыгы һәм энергетик нәтиҗәлелеге өчен мөһим булган җылылык белән тәэмин итүнең муниципаль контрольдәге бәя зоналары кысаларында җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яйсә) модернизацияләү эшләрен контрольдә тоту;»;

2) 9.1 маддәсенең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 17 пунктны өстәргә:

«17) инвалидлар, сәламәтлеге чикле булган затлар өчен спорт һәм физик культура, адаптив спорт һәм адаптив физик культураны үстерүгә теләктәшлек күрсәтү.»;

3)10 маддәнең 1 өлешен:

- түбәндәге эчтәлектәге 4.4 пункты белән тулыландырырга:

«4.4) 2014 елның 28 июнендәге «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 172–ФЗ санлы Федераль законында каралган стратегик планлаштыру вәкаләтләрен;»;

- 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) шәһәрнең икътисади һәм социаль хәлен характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны оештыру һәм аларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимият органнарына тапшыру;»;

4) 28 маддәнең 1 өлеше 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль берәмлекнең социаль-иктисади үсеш стратегиясен раслау;»;

5) 36 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 2.1 өлешен өстәргә:

«2.1. Шәһәр Хакиме вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Хаким сайлау вәкаләт туктатылган көннән башлап алты ай эчендә башкарыла.

Әгәр Шәһәр Советы вәкаләтләре тәмамланырга алты айдан ким вакыт калса, Хаким сайлау яңа сайланган Шәһәр Советының беренче утырышында башкарыла.»;

6) 41 маддәнең 9 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 9.4.1 пунктын өстәргә:

«9.4.1) ««Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә җылылык белән тәэмин итү системасының үсеше, ышанычлылыгы һәм энергетик нәтиҗәлелелелеге өчен мөһим булган җылылык белән тәэмин итүнең муниципаль контрольдәге бәя зоналары кысаларында җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү

объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яйсә) модернизацияләү эшләрен контрольдә тоту;»;

7) 41 маддәнең 15 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктны өстәргә:

«4) инвалидлар, сәламәтлеге чикле булган затлар өчен спорт һәм физик культура, адаптив спорт һәм адаптив физик культураны үстерүгә теләктәшлек күрсәтү.»;

8) 50 маддәнең 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кешенең һәм гражданның хокукларына һәм вазифаларына, муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле узидарә органнары белән төзелгән килешүләр матбугатта рәсми басылган (хәбәр бирелгән) көннән гамәлгә керә.»;

9) 92 маддәнең 3 өлеше 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Шәһәр Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнарының үзара вәкаләтләрен үзгәртүче (федераль законнарга туры китереп Уставка үзгәрешләр кертү, җирле үзидарәнең сайлаулы вазифаи затларын сайлау тәртибе, вәкаләтләре, вәкаләтләр срогыннан тыш) үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге үзгәрешләрне шәһәр Уставына кертү турында хокукый акт кабул иткән Шәһәр Советы вәкаләтләре срогы чыккач үз көченә керә.».

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеге тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2017 елның 25 декабрендә теркәлгән. Дәүләти теркәү номеры № RU 163020002017003.